СОВЕТ СРЕДНЕТИГАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ УРТА ТИГӘНӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Урта Тигәнәле ав.

08.04.2026 № 20

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Урта Тигәнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2014 елның 20 ноябрендәге 126 номерлы «Урта Тигәнәле авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Урта Тигәнәле авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы Нигезләмәне раслау турында» карарының үз көчен югалтуын тану турында**

«Россия Федерациясе Президентының кайбер актларын үзгәртү һәм аларның үз көчләрен югалтуын тану турында» Россия Федерациясе Президентының 2025 елның 31 декабрендәге 1009 номерлы Указына туры китереп,

**Урта Тигәнәле авыл җирлеге Советы карар бирде:**

1. Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Урта Тигәнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының түбәндәге карарларының үз көчен югалткан дип танырга:

- «Урта Тигәнәле авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Урта Тигәнәле авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы Нигезләмәне раслау турында» 20.11.2014ел, №126 карары;
- «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Татарстан

Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы Нигезләмәне раслау турында» Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлеге Советының 20.11.2014ел,№126 карарына үзгәрешләр кертү турында» 20.11.2023 ел, № 40 карары;

- «Урта Тигәнәле авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Урта Тигәнәле авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы Нигезләмәне раслау турында» Советның 20.11.2014ел, №126 карарына үзгәрешләр кертү турында» 26 .06.2024ел, № 58 карары.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (https://alekseevskiy.tatarstan.ru/), Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Урта Тигәнәле авыл җирлеге Башлыгы, Совет рәисе** **И.К.Хәмәтвәлиев**